Год педагога и наставника 2023
Укытучылар һәм остазлар елы

# Безнең мәктәп

**«Боекмас өчен күңелләр, кимсенмәс өчен йөрәк – сез кирәк, укытучылар, безгә һәрчак сез кирәк!»**

**Фәнис Яруллин**

**УКЫТУЧЫМА**

Шытым салып нәни йөрәгемә,
Белем дөньясына озатучы.
Һәр уңышым саен сөенүче
Бары Сез ул, минем
Укытучым!

Елаганда яшьләремне сөртеп
Сабырлыкка мине өйрәтүче.
Әниемдәй ягымлы елмаеп
Сез генәдер шулай эндәшүче.

**Салиха Гаязова.**



**Беренче укытучым**

2-3 битләр

**Минем яраткан укытучым**

4-5 битләр

**Укытучылар турында укытучылар**

6-7 битләр

**Укучылар иҗаты**

8 бит

Кыңгыраулы мәктәп еллары күңелдә кала торган иң шатлыклы һәм мәшәкатьсез мизгелләрнең берсе. Мәктәп кешегә беренче бик мөһим булган белемне генә түгел, беренче тормыш дәресләрен дә бирә. Һәркемгә үзе укыган мәктәп кадерле һәм якын. Безнең мәктәбебез иң матур мәктәпләрнең берсе.Беренче карашка ул башка мәктәпләрдән, бәлки, аерылмыйдыр. Әмма монда күңелгә үтеп керә торган җылылык һәм ниндидер рәхәтлек бар, бу хисләр мәктәпнең бусагасын атлап кергәч тә сине урап алалар кебек. Кайдан килә соң бу җылылык? Бу җылылык безнең икенче әниләребез кебек булып, безне кайгырткан, укыткан, тәрбияләгән укытучылардан килә икән бит! Кадерле укытучыларыбыз, сез булганга гына безнең мәктәбебез нурлы һәм якты .Сездән таралган белем нуры гына аны җылы һәм якты итә. Без һәрвакыт сезнең кайгыртуны тоеп яшибез! Сез дөньядагы иң белемле һәм иң мәрхәмәтле укытучылар! Без сезне яратабыз һәм сезнең белән горурланабыз!

# Беренче укытучым

Гомеремнең тәүге язларыннан,
Әткәм-әнкәм белән янәшә,
Берәү яши һаман күңелемдә,
Үткәннәрдән кайтып эндәшә.

Резеда Валиева





Безнең беренче укытучыбыз Гайфуллина Гөлфинә апа. Беренче тапкыр мәктәпкә килгәч, Гөлфинә апа безне каршы алды.Башта без укыячак класс бүлмәсе белән таныштырды,аннары мәктәпне күрсәтеп чыкты.Ул безне 1нче класстан 4 класска кадәр укытты.Ул безнең кулларыбыздан тотып язарга, укырга, санарга өйрәтте. Яхшы укысыннар дип төрле бүләкләр бирә иде.Кайвакытларда безне ачуланып та ала иде, ахырдан “белемле булсыннар дип орышам бит“ дия иде. Ул дәресләрне кызыклы итеп үткәрә иде, төрле уеннар уйный идек. Бәйрәмнәргә дә кызыклы-кызыклы концерт номерлары әзерли идек. Без беренче укытучыбызны бик яратабыз, хөрмәт итәбез һәм сагынабыз.

**Алукаев Мөхәммәт ,Фахрисламов Фәнис,**

**7 нче сыйныф укучылары**

Шамгунова Гөлшат апа—безнең беренче укытучыбыз. Ул чын мәгънәсендә безнең икенче әниебез булды. Ул безне каләм тотарга ,язарга,хәреф танырга өйрәтте.Шук -шаян ,күзләре янып торган, уйлары уенда булган 6 баланы үзенә каратты.Бездә кеше өчен иң кирәкле сыйфатларны тәрбияләргә тырышты.Олыларны хөрмәтләргә, кечеләрне якларга, кешеләр белән исәнләшергә, ярдәмчел булырга, теләсә нинди очракта да кеше булып калырга өндәде. Без беренче укытучыбызны бик яратабыз! Без Гөлшат апага бик рәхмәтле.

**Габдрашитова Алисә, 9 нчы класс укучысы**





Шайхулова Зөлфия апа- безнең беренче укытучыбыз.Ул бик әйбәт укытучы. Гадел һәм түземле, тыныч һәм ягымлы. Дәресләрне дә аңлаешлы һәм күңелле итеп үткәрә иде. Аңламаган темаларны кат-кат аңлатырга да вакытын кызганмый иде. Аның белмәгән нәрсәсе юк, бөтен сорауларга да җавап таба. Һәрберебезнең хәленә керә , булыша иде. Кайчакларда мәктәп янына алма сатучылар килә иде. Апабыз сатучыдан безгә дип тә, алмалар ала иде. Безгә иң зурларын , иң кызылларын бирә иде. Без шул алмалар өчен ярышып, иң зурларын бүлешә идек. Әлегә вакыйгаларны без бүген дә сагынып искә төшерәбез.Тырышлыгы, түземлеге өчен Зөлфия апага без бик рәхмәтле.

**Шамгунова Айгөл , 8 класс укучысы**



Укытучы! Әлеге сүзне ишеткәч, безне 1 сентябрь көнендә кулдан тотып мәктәпкә алып кергән кеше күз алдына килә. Минем иң беренче, онытылмас укытучым -Гатина Зәйтүнә Хәсән кызы. Ул 1971 елның 17 апрелендә Кармыш авылында туган. Кияүгә чыккач, Әшәлче авылына күченә һәм мәктәпкә укытучы булып урнаша.Безне нәкъ менә Зәйтүнә апа укытты. Ул үзенең эшен яратып, бик теләп башкара.

Без 2016 елнын 1 сентябрендә укырга-кердек. Ул безне бик җылы каршы алды. Безне укырга, язарга, зурларны хөрмәт итәргә , бик күп яхшы эшләр эшләргә өйрәтте. Без Зәйтүнә апаның ачуын чыгарган вакытлар да булгалады. Ачуын чыгарсак, безне оршып та ала иде ,ләкин озакка түгел. Зәйтүнә апа ачуны озак сакламый торган кеше. Ул игелекле, сабыр, уңган, белемле. Бервакыт апабыз авырып китте, аның урынына безне башка укытучылар укытты. Без Зәйтүнә апаны бик юксындык, тизрәк терелсен дип тордык.

Зәйтүнә апа дәресләрне кызыклы итеп алып бара иде. Ел ахырында ул безне гел пикникка, экскурсияләргә алып барды. Пикникта Зәйтүнә апа безгә төрле -төрле кызыклы уеннар, табышмаклар әзерли иде. Бергәләшеп уеннар уйнап ,көнне бик кызыклы итеп уткәрә идек.

Ә хәзер инде без 7 сыйныфта укыйбыз. Башлангыч сыйныфлардан ук күңелләребездә белем алуга омтылыш уятканы өчен без Зәйтүнә апага бик рәхмәтле. Зәйтүнә апа, алдагы көннәрегездә уңышлар, якты көннәр телибез!

# Минем яраткан укытучым

**Якупова Алия,**
**7 нче сыйныф укучысы :**

Мин кечкенәдән рәсем ясарга яратам ,бәлки шуңа күрәдер миңа рәсем дәресләре һәм әлеге фәнне укытучы Гатина Гөлия апа ошый. Аның дәресләрендә, мин үземне иркен тотам һәм үземнең фикерләремне курыкмыйча әйтә алам. Мин Гөлия апаны бик хөрмәт итәм һәм һәрбер дәрескә матур рәсемнәр ясап киләм, шуның өчен ул да безнең сыйныфны хөрмәт итә. Ул үз эшен бик ярата һәм безгә дә кирәкле киңәшләрен бирә. Әле үзенең эшендә генә түгел, ә болай да ул бик яхшы, мәрхәмәтле кеше. Аның белән күп нәрсә турында сөйләшеп тә була һәм шуның өчен мин аны тагын да күбрәк хөрмәт итәм.






**Латыпова Энже,**

**7 нче сыйныф укучысы**:

-Укытучы! Бу сүз һәр кешенең күңеленә бик якындыр дип уйлыйм. Беренче укытучы, яраткан укытучы һәр кешедә дә бар.Минем яраткан укытучым Юнысова Фирүзә апа. Ул татар теле һәм әдәбияте укытучысы. Ул һәр дәресне кызыклы итеп алып бара. Берәр яңа тема өйрәнсәк, яхшылап, җентекләп аңлата. Ул үзенең эшен бик яхшы үти. Фирүзә апа ягымлы, мәрхәмәтле, мөлаем, уңган, бик яхшы кеше. Нәрсә булса да, ул безгә гел булыша, безгә терәк булып тора. Мин аның дәресләрен бик яратам. Мин аның җитәкчелегендә бик күп конкурсларда катнашып, җиңү яуладым.

**Гатина Алсу,**

**7нче класс укучысы :**

-Минем яраткан укытучым Габдуллина Эльмира апа.Ул инглиз теле укытучысы. Инглиз теле минем өчен иң кызыклы дәресләрнең берсе. Ә Эльмира апа ул дәресләрне тагын да кызыклы итеп үткәрә. Без бөтен классыбыз белән аның дәресләрен көтеп алабыз. Дәресләрдә инглизчә сөйләшергә тырышабыз.





**Алукаев Мөхәммәт, 7 нче класс укучысы:**

-Минем яраткан укытучыларым - Шамгунов Самат абый һәм Шамгунова Рәмия апа. Самат абый физкультура һәм технология дәресләрен укыта, ә Рәмия апа биология һәм география укытучысы. Мин әлеге фәннәрне яратып укыйм. Самат абый да, Рәмия апа да белемле, киң күңелле, мәрхәмәтле укытучылар. Дәресләрен кызыклы ,мавыктыргыч итеп үткәрәләр.





# УКЫТУЧЫЛАР ТУРЫНДА УКЫТУЧЫЛАР



## Сез иң гүзәл кеше икәнсез !

Укытучы. Кем генә зур ихтирам белән телгә алмый икән бу исемне. Мәктәптә, уку йортларында белем бирүче, нинди дә булса фән алып баручы, фикерләүче, җәмәгать эшлеклесе, тормышта балаларга үз юлларын табарга булышучы һәм алардан дөньяга караш, инанулар тәрбияләүче, үзенең яшәү тәҗрибәсе белән аерым шәхес тәрбияләүдә тирән эзләр калдыручы, бала күңеленә иң якын кешене – Укытучы дип атыйлар.

Күңелнең бик күп сыйфатлары бар, шул сыйфатларга ия булмый торып, чын укытучы булырга мөмкин түгел. Бу сыйфатлар арасында иң беренчесе – баланың рухи дөньясына үтеп керә белү. Балаларны чын күңелдән яраткан, хөрмәт иткән укытучы гына чын укытучы була ала.

Үзем мәктәп системасында 30 елдан артык эшләсәм дә мәктәп еллары, сабакташлар, сыйныф җитәкчесе гел күз алдында тора. Без мәктәпне 30 укучы тәмамладык. Очрашканда һәрвакыт мәктәбебезне, укытучыларны, сыйныф җитәкчесен искә алабыз.

Сүз сыйныф җитәкчесе, мәктәптә күп еллар буе география,биология фәнен укыткан, олы хөрмәткә ия – Миншина Кәшифә Ахмадулла кызы турында булыр.

Кәшифә апа бик тырыш, хыялга бай, фантазияле, үз һөнәрен бик ярата торган, гел эзләнеп, яңа технологияләр кулланып, төрле тәҗрибәләр үткәреп,бездә укытучы һөнәренә мәхәббәт тәрбияләүче олы зат булды.

Аның үткәргән тәрбия сәгатьләре, өйрәткән җырлары, биюләре минем күңелемдә гомер буе саклана. Балаларны яратуы, үз теләгенә ирешүчән булганы өчен мин сыйныф җитәкчемне хөрмәт итәм һәм үземдә дә шушы сыйфатларны булдырырга тырыштым..

Кәшифә апаны безнең икенче әниебез дип әйтеп була иде. Әниләребез кебек үк, ул да безне кирәк вакытта мактый, ә кайчак ачулана да белә иде. Ләкин без аңа беркайчан да үпкәләмәдек, ә киресенчә, хатабызны төзәтергә һәм апа әйткәнчә эшләргә тырыштык. Ул һәрвакыт безнең өчен кайгыртып яшәде. Берәребез авырып китсә, аның күңеле тыныч түгел иде. Безне тизрәк терелтер өчен: «Сиңа моны эшләргә ярамый, син мондый дару эч»,- дип киңәшләрен бирә иде. Ә инде киңешләре безгә файда китерсә, ул бик нык сөенә дә белә иде.

Кәшифә апа безнең белән кызыклы темаларга сөйләшергә ярата иде. Дәресләрдә буш вакыт калса, ул безгә үзе яки башка кешеләр белән булган кызыклы хәлләрне сөйли иде. Ул шулай үзенчә безне олы тормыш юлына әзерләгәнен хәзер генә аңладым мин.

Бакчада эшләү – Кәшифә апаның яраткан эшләреннән берсе иде. Апабыз мәктәп бакчасы өчен җаваплы. Шуңа күрә безнең класска еш кына шунда эшләргә туры килә иде. Апа безне бакчаны тәртиптә сакларга, яшелчә һәм башка культураларны дөрес итеп утыртырга, аларга күпме су сибәргә кирәк икәнен өйрәтә. Ел саен ул яңа сортларны үстереп карый, аннары кайсылары яхшы уңыш бирә, шуларның орлыкларын җыя иде. Бу юл белән ул бездә хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән.

Бүгенгесе көндә дә хөрмәткә лаек сыйныф җитәкчебез сау сәламәт, балалары, оныклары бәхетенә төренеп яши. Без аның өчен бик шатбыз.

Киләчәктә дә иәнлектә.саулыкта ,тынычлыкта, шатлыкта яшәвен теләп калабыз.

**Якупова Гөлнур Фатыховна сөйләгәннәрне Гатина Алсу язып алды**

# УКЫТУЧЫЛАР ТУРЫНДА УКЫТУЧЫЛАР



## Остазлар остазы

Сүзем остазларның остазы Габдуллина Зәйнәп Вагыйз кызы турында.

Зәйнәп Вагыйз кызы Габдуллина- 40 елга якын гомерен Кармыш авылы мәктәбендә балаларга математика фәнен укыткан, бик куп укучыларга төпле белем һәм тәрбия биргән олы хөрмәткә лаек укытучы. Ул уз районыбызның Лашман авылында туып-үскән, Казан дәүләт педагогия институтының математика- физика бүлеген тәмамлап, кулына диплом алганнан соң, лаеклы ялга чыкканчы бар белемен, хезмәтен Кармыш мәктәбенә багышлады. Ләкин ул хезмәт юлында укучылар өчен генә түгел, бик күп яшь укытучылар өчен дә остаз булды.

Без, хезмәт юлын яна башлап җибәрергә җыенган бер төркем яшь кызлар, мәктәп бусагасын атлап кердек. Кулларыбызда диплом булса да, безнен әле коллективта, балалар белән эшләү тәҗрибәсе юк, дәрес бирүләр дә практика чоры белән генә чикләнгән иде. Менә шул вакытта без Зәйнәп Вагыйз кызынын тирән белемле укытучы гына түгел, чын җитәкче, оештыручы, остаз да икәнен аңладык, тойдык.

Зәйнәп Вагыйз кызы безне, директор буларак, елмаеп каршы алды. Шул көннән башлап ул безнең төп таянычыбыз, ышанычлы киңәшчебез булды. әле ул вакытта үзе дә яшь булуына карамастан, безнен һәр туган соравыбызга нигезле җавап бирде, барысын да тәфсилләп аңлатты, һичкайчан «Белмим!»- димәде. Укыту һәм тәрбия процессы күпкырлы, зур җаваплылык таләп итә торган өлкә. өлкән хезмәттәшебез безгә эш барышында килеп туган четерекле мәсьәләләрне дөрес итеп хәл иту юлларын да күрсәтте. Үзе һәрвакытта җыйнак, төгәл, пөхтә булды, сүзен үлчәп сөйләде. Анын кабинетында идеаль тәртип хөкем сөрде. Гади, ләкин зәвыклы итеп киенде. Укучыларга, ата-аналарга һәм безгә – яшь укытучыларга - карата да һәрвакыт итәгатьле, гадел булды, тиеш вакытта үз сүзен кистереп әйтте. Без аны укытучы, директор итеп кенә түгел, үз апабыз кебек тә якын күрдек, серләребезне дә уртаклаштык.

Вакыт уза, белем бирүгә дә таләпләр үзгәрә. Мәктәпләргә дә компьютерлар, электрон дневниклар килеп керде. Бу өлкәне дә Зәйнәп Вагыйз кызы тиз арада үзләштереп, балаларга белем бирүдә яна технологияләрне уңышлы файдаланды. Бу шулай ук барыбыз өчен дә матур үрнәк булды. Доньяда барган хәлләрдән, мәгариф өлкәсендәге яңалыклардан ул һәрвакыт хәбәрдар иде, профессиональ яктан үз-үзен үстерү өстендә өзлексез эшләде.

«Тәҗрибә байлыгы - тузмас байлык», - дигәннәр борынгылар. Озак еллар бергә эшләү дәверендә үз тәҗрибәсе белән уртаклашуы, безгә терәк булганы өчен без бүген дә Габдуллина Зәйнәп Вагыйз кызына рәхмәтлебез, аны хөрмәт һәм сагыну хисе белән искә алабыз!

**Сальманова Миләүшә Нурхамәт кызы сөйләгәннәрне Якупова Алия язып алды**

УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

ШИГЪРИ ТӘЛГӘШЛӘР

**БЕРЕНЧЕ УКЫТУЧЫМ**

И,беренче укытучым ,
Җитәкләп син нәни кулдан,
Сабыр гына алып киттең
Мәктәп дигән серле юлдан
Шатландырдың ,уйландырдың,
Күңелләргә куйдың канат.
Матурлыкка ,яктылыкка
Омтылдык без сезгә карап
Атларбыз без тормыш буйлап ,
Тотып сезнең киңәшләрне
Намус белән үтәрбез гел
Барлык сынау һәм эшләрне

**Латыпова Энже**

**УКЫТУЧЫМ**

Туган мәктәп ,укытучы...
Нинди якын ,матур сүзләр.
Сорау биреп,җавап көтеп
Карый сезгә күпме күзләр!
Алдамыйсыз, сынатмыйсыз.
Бер сорау калмый җавапсыз
Мәңге бетмәс сорауларга
Кайлардан җавап табасыз?!
Мин телимен сезгә теләк:
Сау-сәламәт,шат булыгыз!
Җаннарыгыз тыныч булсын,
Уңышлы булсын юлыгыз!

**Шамгунова Айгөл**




**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Советлар Союзы Герое Бари Габдрахман улы Габдрахманов исемендәге Кармыш төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**

**Газетаны гамәлгә куючылар:7 нче сыйныф укучылары**